ГЛАВА
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2025 Баулы шәһәре № 223

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Татар Кандызы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар, (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәсе, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 17 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Татар Кандызы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты (алга таба - Проект) буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Проект буенча гавами тыңлаулар инициаторы – Баулы муниципаль районы Башлыгы.

3. Гавами тыңлауларны уздыруны 2025 елның 29 декабреннән 2026 елның 29 гыйнварына кадәр билгеләргә.

4. Гавами тыңлауларда каралырга тиешле Проект экспозициясен 2025 елның 29 декабрендә ачарга:

4.1. Экспозицияне уздыру урыны:

- Татарстан Республикасы Баулы районы Татар Кандызы авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Татар Кандызы авылы, Совет ур., 166 й. адресы буенча;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә www.bavly.tatarstan.ru Баулы муниципаль районы сайтында.

4.2. Экспозицияне карау режимы:

- Татарстан Республикасы Баулы районы Татар Кандызы авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Татар Кандызы авылы, Совет ур., 166 й. адресы буенча.

Эш көннәрендә Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 сәгатькә кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Гавами тыңлауларда катнашучылар 2025 елның 29 декабреннән 2026 елның 29 гыйнварына кадәр эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- язмача рәвештә гавами тыңлауларны оештыручыга: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, 101 каб. адресы буенча;

- Bauly.arch@mail.ru электрон пачтасы аша.

6. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитетын (алга таба – гавами тыңлауларны оештыручы) билгеләргә.

7.Гавами тыңлауларны оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча гавами тыңлауларны уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Проект буенча гавами тыңлаулар башлану турында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге Татар Кандызы авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» челтәрендәге Баулы муниципаль районы сайтында (www.Bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга;

7.3. Экспозицияләрне Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Татар Кандызы авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында 2025 елның 29 декабреннән 2026 елның 29 гыйнварына кадәр эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 сәгатькә кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru оештырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы И.И. Гозәеров